Аксубай муниципаль районы Беловка авыл жирлеге Советы
423050 Аксубай районы,Яңа Үзи авылы,
Мәктәп урамы, 7 нче йорт

Совет Беловского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
423050 Аксубаевский район,с.Новое Узеево улица Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru, sovet.belov@mail.ru*

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы
**КАРАР**

№3 13.11.2023 ел

"Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең
Беловка авылында гражданнарның
үзара салым чараларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2023 елның 22 ноябрендә ТР, Аксубай районы, Беловка авылы, Полевая урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Беловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләнсен.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга::
:"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Беловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ,( 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына мобилизацияләнгән, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсуслаштырылган хәрби операция (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, үз теләге белән китүчеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:
**1.Беловка авыл җирлеге Беловка авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,тоту (Беловка торак пункты чикләрендә юл япмасын төзү, шул исәптән: туфракны күтәрү, гредировкалау, вак таш

салу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләүне тигезләү, вак таш сатып алу, авыл юлларына вак таш салу);

Беловка авыл җирлеге Беловка торак пункты чикләрендә юлны кышкы тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр һәм җиһазлар сатып алу; килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**2.Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру**:

-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрен ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3**. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп):**

урам яктыртуны оештыру (Беловка торак пункты чикләрендә урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен килешү буенча товарлар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов

СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ